ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 71 23.09.2021ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәне раслау хакында.

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы»08.11.2007 ел, № 259-ФЗ Федераль законның 3.1 статьясы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 08.11.2007 ел, 257-ФЗ Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 ел, № 248-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы кушымта итеп бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, ләкин 2022 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәләр» 5нче бүлегенең нигезләмәләреннән тыш.

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәләр» 5 бүлегендәге нигезләмәләр 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм http:/pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат порталында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе

К.К.Гыйлманов